# Беркетмә № 4

Мамадыш районы Җөри балалар бакчасының
ата-аналар җыелышы беркетмәсе.

Үткәрү вакыты: 28.05.2021 ел.

Катнаша: 6

Җыелышның рәисе: Михайлова А.П.

Сәркатибе: Бинкова Х.А.

Көн тәртибе:

1. Җәйге чорда балалар бакчасының эш тәртибе . Мөдир Абузарова Р.М.
2. 2020-2021 нче уку елына йомгак. Тәрбияче Михайлова А.П.чыгышы.
3. Әти-әниләр белән инструктаж уткәрү. Тәрбияче Михайлова А.П.
4. Нигезләмәләргә(Положения) үзгәрешләр кертү хәм кабул итү.Мөдир Абузарова Р.М.

**Беренче көн тәртибе** буенча сүз мөдир Абузарова Р.М.га бирелде. Ул җәйге чорда балалар бакчасының эш тәртибе белән таныштырды. Балалар саны җитмәү сәбәпле (регламент буенча 10 бала), 1 нче июньнән балалар бакчасы җәйге ялга ябыла. Җәйге чорда бакчага косметик ремонт ясау, балалар мәйданчыгын төзекләндерү күздә тотыла.

6 гаиләнен 2се бакчаның эшен туктатуына каршы чыкты: Бинкова Х.А., Гаврилова М.Н., калган 4 гаилә үзләренең ризалыкларын бирделәр.

Карар: мөдир Абузарова Р.М.га бакчага косметик ремонт һәм балалар мәйданчыгын төзекләндерү өчен кирәкле материал белән тәэмин итәргә. Күпчелек гаиләләрнең фикерен хуплап Җөри балалар бакчасын җәйге ялга туктатырга.

**Икенче көн тәртибе** буенча сүзне тәрбияче Михайлова А.П. алды. Ул мәктәпкә хәзерлек төркеме балаларының диагностика нәтиҗәләре белән таныштырды. Ел дәвамында әти-әниләрнең һәм балаларның балалар бакчасында үткәрелгән мероприятиеләрдә, бәйрәмнәрдә актив катнашуларын билгеләп үтте. Иң актив гаиләләргә мактау кәгазьләре тапшырды.

Карар: мониторинг нәтиҗәләрен канәгатьләнерлек дип бәяләргә.

**Өченче көн тәртибе** буенча тәрбияче Михайлова А.П.га бирелде.Ул әти-әниләр белән инструктаж үткәрде. Җәйге чорда балаларга карата аеруча сак булырга, юл йөрү кагыйдәләрен төгәл үтәргә, кояш сугудан саклану өчен һәрчак баш киеменнән йөртергә, ялгыз гына урамга, кибетләргә җибәрмәскә, чит кешеләр белән аралашмаска кирәклеген аңлатты.

Карар: тәрбияче Михайлова А.П.га әти-әниләр белән инструктажның үтәлешен барларга.

**Дүртенче көн тәртибе** буенча сүз мөдиргә бирелде.Ул нигезләмәләр(Положения) белән таныштырды:

1. Положение о порядке приема, перевода и отчисления воспитанников.
2. Положение о режиме занятий.
3. Положение о образовательной деятельности воспитанников.
4. Положение о порядке формирования, ведения и хранения личных дел воспитанников.
5. Положение учёта мнения родителей (законных представителей) воспитанников при принятии локальных нормативных актов, затрагивающих права воспитанников.

Карар:нигезләмәләрне (Положения) кабул итәргә, шулар нигезендә эшне алып барырга.

Рәисе: Михайлова А.П.

Сәркатибе: Бинкова Х.А.